КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 656

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә граждан-нарга түләүсез медицина ярдәме күрсә-түнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы терри-ториясендә гражданнарга түләүсез меди-цина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июнь, 445 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең егерме җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация, шул исәптән тирәнтен үткәрелә торган – халыкның зуррак яшьтәге аерым төркемнәре (18 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк), шул исәптән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау

министрлыгы тарафыннан расланган тәртипләр нигезендә көндезге формада мәгариф оешмаларында белем алучы, эшләүче һәм эшләмәүче гражданнар;»;

III бүлекнең 2 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«профилактик чаралар (Программаның II бүлегендә күрсәтелгән гражданнарга һәм аларның аерым категорияләренә профилактик медицина тикшерүләрен кертеп), шул исәптән диспансеризация кысаларында, шул исәптән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган тәртипләр нигезендә диспансеризация, шул исәптән тирәнтен үткәрелә торган диспансеризация;»;

Программаның VI бүлегендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Халыкның аерым категорияләре өчен диспансеризация үткәрү, балигъ булмаганнарга профилактик тикшерүләр үткәрү шартлары һәм сроклары

Халыкны диспансеризацияләү чаралар комплексыннан, шул исәптән табиб-белгечләр тарафыннан медицина тикшерүеннән һәм халыкның аерым төркемнәренә, шул исәптән балигъ булмаганнарның аерым категорияләренә карата гамәлгә ашырыла торган тикшерүнең кирәкле ысулларын куллануда гыйбарәт. Халыкны диспансеризацияләү авыруларны иртәрәк ачыклауга һәм профилактикалауга юнәлдерелгән.

Балигъ булмаганнарга профилактик медицина тикшерүләре патологик хәлне, авыруларны һәм аларның үсеш рискы факторларын иртәрәк (үз вакытында) ачыклау, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне медицинада кулланмау максатларында, шулай ук сәламәтлек төркемнәрен билгеләү һәм балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары яисә башка законлы вәкилләр өчен тәкъдимнәр эшләү максатларында, билгеләнгән яшь чорларында уздырыла.

Балигъ булмаганнарны диспансеризацияләү һәм аларга профилактик медицина тикшерүләре, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясында билгеләнгән таләпләрне үтәп, балигъ булмаганнарның (аның ата-анасының яки башка законлы вәкиленең) мәгълүмат алу характерындагы ирекле ризалыгы булу шарты белән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив документларында расланган программалар һәм сроклар нигезендә Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмаларында уздырыла.

Медицина оешмасында кирәкле табиб-белгечләр, лаборатор һәм функциональ тикшеренүләр булмаганда, халыкка, шул исәптән балаларга профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация үткәрү өчен белгечләр консультацияләре һәм диагностик тикшеренүләр башка медицина оешмаларының белгечләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итеп үткәрелергә мөмкин.

Табиб-белгечләр тарафыннан тикшерүләр, үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, профилактик чаралар үткәрү һәм дәвалау буенча

табиб-белгечләрнең тәкъдимнәре, шулай ук сәламәтлек торышына комплексы бәя бирелгән гомуми бәяләмә билгеләнгән тәртиптә медицина документациясенә кертелә.

Профилактик чаралар үткәрү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гражданнарга профилактик медицина тикшерүләре, диспансеризация, шул исәптән кичке сәгатьләрдә һәм шимбә көнендә үтүне оештыруны тәэмин итә, шулай ук гражданнарга медицина тикшеренүләре өчен дистанцион язылу мөмкинлеген бирә. Иминләштерелгән затларга профилактик тикшерүләр, диспансеризация һәм диспансер күзәтүләрен үткәрү тәртибе, шул исәптән кичке сәгатьләрдә һәм шимбәдә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Профилактик чаралар шул исәптән халыкның төп үлү сәбәпләрен формалаштыра торган кан әйләнеше системасы авыруларын һәм онкологик авыруларны ачыклау өчен дә оештырыла.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гражданнар профилактик медицина тикшерүләрен (диспансеризацияне кертеп) уза ала торган медицина оешмалары турында мәгълүмат урнаштыра.

2021 елның 1 июленнән, профилактик медицина тикшерүләренә һәм диспансеризациягә өстәмә итеп, яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авырган гражданнар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планлы чорына гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасының 4 нче кушымтасында китерелгән исемлек буенча тикшеренүләрне һәм башка медицина катнашуларын үз эченә алган тирәнтен диспансеризация (алга таба – тирәнтен диспансеризация) узарга хокуклы.

Тирәнтен диспансеризация шулай ук яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авырган турында мәгълүматлары булмаган гражданның инициативасы буенча да үткәрелергә мөмкин.

Тирәнтен диспансеризацияне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары исемлеге һәм аларның эш тәртибе түбәндәгеләргә карата урнаштырыла:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы медицина оешмаларына карата – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (алга таба – бердәм портал);

федераль медицина оешмаларына карата – медицина оешмасын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук бердәм порталда.

Гражданнарны тирәнтен диспансеризация (беренче чиратта тирәнтен диспансеризация уза торган категорияләрне кертеп) узарга җибәрү тәртибе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Медицина оешмалары, шул исәптән федераль башкарма хакимият органнары ведомствосы буйсынуындагы һәм беркетелгән контингенты булган медицина оешмалары гражданнарны тирәнтен диспансеризация (беренче чиратта тирәнтен диспансеризация уза торган категорияләрне кертеп) узарга җибәрү тәртибе нигезендә

тирәнтен диспансеризация узарга тиешле гражданнар исемлегеген төзи һәм аны Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына җибәрә. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды мәҗбүри медицина иминиятенең дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә әлеге исемлекләрне тирәнтен диспансеризация узарга тиешле гражданнар иминләштерелгән медицина оешмаларына җиткерә.

Гражданнарга тирәнтен диспансеризация узу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү бердәм порталны, радиотелефон элемтәсе челтәрен (смс-хәбәрләр) һәм һәркем файдалана торган башка элемтә чараларын кулланып, иминият медицина оешмаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны тирән диспансеризациягә язу билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән бердәм порталдан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Медицина оешмалары бер көн эчендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасының 4 нче кушымтасындагы 1 пункты нигезендә тирәнтен диспансеризациянең беренче этабындагы барлык тикшеренүләрне һәм башка медицина катнашуларын башкару исәбеннән чыгып, гражданның тирәнтен диспансеризация узуын оештыра.

Гражданның йогышлы булмаган хроник авырулары, шул исәптән авырып уздырган яңа коронавирус йогышлы авыруы белән бәйле авырулары булуы ачыкланган очракта, тирәнтен диспансеризация нәтиҗәләре буенча граждан диспансер күзәтүенә билгеләнгән тәртиптә куела, күрсәткечләр булганда аңа Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле дәвалану һәм медицина тернәкләндерүе буенча ярдәм күрсәтелә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дару препаратлары бирелә.

Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды Татарстан Республикасының Медицина иминияте федераль территориаль фонды белән, шул исәптән тирәнтен диспансеризация узуны һәм аның нәтиҗәләрен мониторинглауны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча да хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

Профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация, шул исәптән тирәнтен диспансеризация узу кысаларында медицина тикшеренүләрен үткәрү өчен кирәк булганда, медицина оешмаларының махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләре җәлеп ителергә мөмкин.

Профилактик медицина тикшерүләрен, шул исәптән диспансеризация (тирәнтен диспансеризацияне кертеп) кысаларында уздыру буенча медицина хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, алар өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгыннан чыгып эшләүне исәпкә алып, Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу куркынычы барлыкка килү шартларында мәҗбүри медицина иминиятенең база программасын тормышка ашыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.»;

Программаның VIII бүлегендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын тормышка ашырганда медицина ярдәме күрсәткән өчен түбәндәге түләү ысуллары кулланыла:

амбулатор шартларда күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә:

медицина ярдәме күләме берәмлеге – медицина хезмәте күрсәткән, булган, мөрәҗәгать иткән (тәмамланган очрак) өчен түләүне берләштереп, беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативы буенча (компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр үткәрү чыгымнарыннан, шулай ук фельдшерлык, фельдшер-акушерлык пунктларын финанслар белән тәэмин итү акчасыннан тыш);

медицина оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен (медицина ярдәме күләме күрсәткечен кертеп) исәпкә алып, башка медицина оешмаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме (медицина ярдәме күләме берәмлеге өчен) чыгымнарын кертеп, беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативы буенча (компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр үткәрү чыгымнарыннан, шулай ук фельдшерлык, фельдшер-акушерлык пунктларын финанслар белән тәэмин итү акчасыннан тыш);

медицина ярдәме күләме берәмлеге – медицина хезмәте күрсәткән, булган, мөрәҗәгать иткән (тәмамланган очрак) өчен (иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъектыннан читтә, шулай ук беркетелгән затлар булмаган кайбер медицина оешмаларында күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә кулланыла);

медицина ярдәме күләме берәмлеге – медицина хезмәте күрсәткән өчен (кайбер диагностика (лаборатория) тикшеренүләре – компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр өчен түләгәндә кулланыла);

тирәнтен диспансеризациянең I этабын үткәрү кысаларында түбәндәге тикшеренүләрдән һәм медицина катнашуларыннан гыйбарәт комплекслы булган өчен: хәрәкәтсезлек хәлендә канның кислород белән туенуын үлчәү (сатурация), спирометрия яки спирография үткәрү, канның киңәйтелгән гомуми (клиник) анализы, канның биохимик анализы (холестерин дәрәҗәсен, түбән тыгызлыктагы липопротеиннар, С-реактив аксым дәрәҗәсен тикшерүне, канда аланинаминотрансферазлар активлыгын, канда аспартатаминотрансферазлар активлыгын, канда лактатдегидрогеназ активлыгын билгеләү, канда креатив дәрәҗәсен тикшерүне кертеп);

тирәнтен диспансеризациянең I этабын үткәрү кысаларында медицина ярдәме күләме берәмлеге – медицина хезмәте күрсәткән өчен (6 минутлык йөрү тесты һәм/яки канда Д-димер концентрациясен билгеләү);

тирәнтен диспансеризациянең II этабын үткәрү кысаларында медицина ярдәме күләме берәмлеге – медицина хезмәте күрсәткән өчен (эхокардиография, үпкәләрнең компьютер томографиясе үткәргәндә, түбән очлыкларның кан тамырларын дуплексны сканерлаганда);

стационар шартларда күрсәтелгән медицина ярдәме өчен, шул исәптән махсуслаштырылган медицина оешмаларында (структур бүлекчәләрдә) медицина тернәкләндерүе өчен түләгәндә:

авыруларның тиешле төркеменә (шул исәптән авыруларның клиник-статистик төркемнәренә) кертелгән авыруны дәвалауның тәмамланган очрагы өчен;

пациентны башка медицина оешмасына күчергәндә, медицина ярдәме күрсәтүнең өзелгән очрагы, пациент алга таба дәваланудан язмача баш тартканда аны медицина оешмасыннан билгеләнгән вакыттан алда чыгару, үлгәндә, шулай ук диагностика тикшеренүләрен үткәргәндә, диализ хезмәтләрен күрсәткәндә медицина хезмәте күрсәтүнең өзелгән очрагы өчен;

көндезге стационар шартларында күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләгәндә:

авыруларның тиешле төркеменә (шул исәптән авыруларның клиник-статистик төркемнәренә) кертелгән авыруны дәвалауның тәмамланган очрагы өчен;

пациентны башка медицина оешмасына күчергәндә, медицина ярдәме күрсәтүнең өзелгән очрагы, пациент алга таба дәваланудан язмача баш тартканда аны медицина оешмасыннан билгеләнгән вакыттан алда чыгару, үлгәндә, шулай ук диагностика тикшеренүләрен үткәргәндә, диализ хезмәтләрен күрсәткәндә медицина хезмәте күрсәтүнең өзелгән очрагы өчен;

медицина оешмасыннан читтә күрсәтелгән ашыгыч медицина ярдәме өчен түләгәндә (ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, шулай ук медицина эвакуациясе булганда транспорт чарасында медицина ярдәме бригадасын чакыру урыны буенча) – ашыгыч медицина ярдәмен чакырган өчен түләү белән бергә җан башына финанслау нормативы буенча.

Профилактик медицина тикшерүләренә (шул исәптән диспансеризация кысаларында) түләү беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативы күләме кертелә һәм медицина оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпкә алып (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән медицина тикшеренүләре күләме нигезендә һәм «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектындагы «Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проектының халыкны профилактик медицина тикшерүләренә җәлеп итү буенча максатчан күрсәткечләрне исәпкә алып, медицина ярдәме күләме күрсәткечләрен кертеп) гамәлгә ашырыла.

Амбулатория, стационар шартларда һәм көндезге стационар шартларында медицина ярдәме, шулай ук медицина тернәкләндерүе күрсәтелә торган бүлекчәләр составындагы медицина оешмаларында медицина ярдәменә түләгәндә, медицина ярдәме күләме күрсәткечләрен кертеп, медицина оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпкә алып, әлеге медицина оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган

медицина ярдәменең барлык төрләре һәм шартлары буенча медицина ярдәменә түләүне кертеп, мондый медицина оешмасына беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативы буенча түләү ысулы кулланылырга мөмкин. Шул ук вакытта амбулатор шартларда медицина ярдәмен финанслар белән тәэмин итү чыгымнарыннан компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр үткәрү чыгымнары, шулай ук фельдшерлык, фельдшер-акушерлык пунктларын финанслар белән тәэмин итү акчасы төшереп калдырыла.

Беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативы шул исәптән, телемедицина технологияләрен кулланып, медицина ярдәме күрсәтү чыгымнарын да үз эченә ала.

Амбулатор шартларында медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмалары арасында кайбер диагностика (лаборатория) тикшеренүләре (компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр) күләмен бүлү медицина оешмасының медицина эшчәнлегенә булган лицензиясендә тиешле эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) күрсәтмәләр булганда гамәлгә ашырыла.

Кайбер диагностика (лаборатория) тикшеренүләрен (компьютер томографиясе, магнит-резонанс томографиясе, йөрәк-кан тамырлары системасын ультратавыш белән тикшерү, онкологик авыруларны диагностикалау һәм яман шеш авыруына каршы дару белән дәвалау ысулын сайлап алу максаты белән биопсия (операция) материалына эндоскопик диагностик тикшеренүләр, молекуляр-генетик тикшеренүләр һәм патологоанатомик тикшеренүләр) билгеләү беренчел медицина-санитария ярдәме, шул исәптән беренчел махсуслаштырылган ярдәм күрсәтүче, дәвалаучы табиб тарафыннан медицина күрсәткечләре булганда Программада билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

Программаның IX бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тирәнтен диспансеризацияне финанслар белән тәэмин итү гамәлгә ашырыла, тирәнтен диспансеризациягә түләү өчен Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар исәбеннән башкарыла.»;

Программага 1 нче кушымтаның 97, 171, 190 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин